| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СТАРОСТУДЕНЕЦКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ СУЫКСУ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.08.2026 № 18

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның 05 февралендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге территориясендә юк ителә торган (киселә торган) яшел үсентеләр бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү методикасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның 05 февралендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге территориясендә юк ителә торган (киселә торган) яшел үсентеләр бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү методикасын раслау турында» карарына (15.07.2026 № 15 ред.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга Кушымтаның 2 бүлегенә кушымта нигезендә 6 нчы таблица өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм җирлекнең рәсми сайтында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районының
Иске Суыксу авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе М.М. Дәүләтшин

карарга кушымта

6 нчы таблица

Үсемлекләрнең деградация коэффициенты кдның әһәмияте

| Үсемлекнең торышы (хәле) | Деградация дәрәҗәсе | кдның әһәмияте |
|---|---|---|
| Һәлак булган, тулысынча корыган (тулы деградация, юк ителгән) | 100% | 5 |
| Һәлак булучы, корып бетеп баручы (шактый деградация, үстерергә калдырып булмый) | 99%-90% | 2,5 |
| Көчсезләнеп, хәлсезләнеп баручы (көчле деградация) | 89%-60% | 2 |
| Көчле көчсезләнгән, хәлсезләнгән (уртача деградация) | 59%-30% | 0,9 |
| Уртача көчсезләнгән, хәлсезләнгән ( аз деградация) | 29%-10% | 0,5 |
| Яхшы, сәламәт (зур булмаган деградация) | 9%-1% | 0,1 |